**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 29 сентябрендәге 3253 номерлы карары**

**Россия премьер-лигасы командалары «Рубин» футбол командасы (Казан шәһәре) һәм «Зенит» футбол командасы (Санкт-Петербург шәһәре) арасында 2025/2026 футбол буенча Россия чемпионаты матчын әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең урам-юл челтәре буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында**

Россия премьер-лигасы командалары «Рубин» футбол командасы (Казан шәһәре) һәм «Зенит» футбол командасы (Санкт-Петербург шәһәре) арасында 2025/2026 футбол буенча Россия чемпионаты матчын әзерләү һәм уздыру чорында куркынычсызлыкны тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм:**

1.1. ихтыяҗ булганда, 2025 елның 30 сентябрендә 14:00 сәгатьтән 22:00 сәгатькә кадәр түбәндәге участокларда транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен чикләүне кертергә:

1.1.1. Чистай урамында, А.Бичурин урамыннан Ямашев проспектына кадәр, А.Бичурин урамы ягыннан хәрәкәт иткәндә (С.Хәким урамы юнәлешендә Ф.Әмирхан урамына чыгу юлыннан тыш);

1.1.2. С.Хәким урамында, Ф.Әмирхан урамыннан Чистай урамына кадәрге участокта (ике юнәлештә);

1.1.3. Ямашев проспектында, Адоратский урамыннан Себер Тракты урамына кадәрге участокта (ике юнәлештә);

1.1.4. Академик Арбузов урамында, Журналистлар урамыннан Ямашев проспектына кадәрге участокта, Журналистлар урамы ягыннан хәрәкәт иткәндә;

1.1.5. Чистай урамында, Ямашев проспектыннан Адоратский урамына кадәрге участокта, Ямашев проспекты ягыннан хәрәкәт иткәндә;

1.1.6. Гаврилов урамындагы дублер юлда, Маршал Чуйков урамыннан Чистай урамына кадәрге участокта;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыруда һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплауда ярдәм күрсәтергә;

1.2.2. транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.2.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм МТС.URENT) һәм велосипедлар («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарда күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю эшен оештырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе (Р.Х.Шәмсетдинов), Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе (Р.Р.Фәтхетдинов) белән берлектә юлларны йөк техникасы яки таранга каршы блоклар белән ябу эшен оештырырга;

1.4. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**